культура-агарту керәшен газетасы

# Туганайлар

№13 (521)
11 июль
2024 ел

. 2002 елның 5 октябреннән бирле чыга .

. яңалыкларны **www.tuganaylar.ru** сайтыннан һәм социаль челтәрләрдән укыгыз . 12+

# Җырлы Питрау – чәчәкле җәйнең яме



● *Питрау чибәрләре – Мамадыш районыннан (сулдан уңга) Светлана Иванова, Алёна Архипова һәм Алёна Зайцева.*

**Бүгенге санда:**

**ҖӨРИ КУНАК КӨТӘ**

Мамадыш районының Җөри авылы республикакүләм Питрау бәйрәмендә дистәләрчә мең кунак каршы ала

3нче бит

**ЫРУ ҖЫЕНЫ**

Элгәре киңәш-табыш итү урыны булган ыру җыеннары авылларның престол бәйрәменә башлангыч биргән

5нче бит

**ДУСМАНОВЛАР – ПИТРАУ ПАРЫ**

Тукай районының Борды авылында яшәүче Алёна һәм Макар Дусмановлар ун ел элек кавышканнар, кәбен койдырганнар

6нчы бит

## Тырлаудагы җыен тәртибе

***13 июль көнне 18 сәгатьтә Мамадыш районының Җөри авылы янәшәсендәге Тырлау аланында республикакүләм "Питрау" керәшен мәдәнияте фестивале була.***

Бәйрәмдә кызыклы уеннар һәм ярышлар оештырыла, төрле мәйданчыклар эшли.

**16.00-20.00 сәгатьтә** – "Айбагыр" балалар мәйданчыгы;

**17.00-18.00** – "Чаптар" атлар чабышы, "Тырлау" Җөри җәрминкәсе, зур сәхнәдә – "Питрау җыруы";

**18.00-19.00** – Питрау җыенын ачу тантанасы, "Түгәрәк уен";

**19.00-24.00** сәгатьтә бәйрәм кунаклары түбәндәге мәйданчыкларны, алардагы тамаша һәм уеннарны карый алалар: "Батыр" милли көрәше; "Туганайлар" керәшен йорт-җире; "Питрау түгәрәк уены" фестивале; "Кряшен чибяре" конкурсы; "Питрау уеннары"; "Димче" танышу аланы; "Алан" табигать бүләкләре; "Тәбикмәк" керәшен сыйлары; "Җәшләр җыены" мәйданы. Бу вакытта Питрау музеенда "Гасырларда безнең җөзебез" фотокүргәзмәсе эшли. "Тәпи чишмәсе җыры" фотозонасы да була. Елгадагы "Ылыяда уен" да күңелле үтәчәк.

**20.00-23.00** – Гармунга җырлашыек! ("Айбагыр" мәйданчыгында);

**23.00-24.00** – "Арулану учагы" янында уеннар;

**24.00** – Бәйрәм фейервергы.

Республикакүләм "Питрау" керәшен мәдәнияте фестивале Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев ярдәме белән үткәрелә.

0+

Көндәлек яңалыкларны, чаралардан фото һәм видеоязмаларны әлеге QR-код аша **tuganaylar.ru** сайтына кереп укыгыз.

ҮЗ ҖӨЗЕ, ҮЗ ТӨСЕ

# Владимир авылы шагыйрьләре

*Җырчы Җәкәү йортында Мамадыш районының Владимир авылыннан чыккан шагыйрьләр Георгий Ибушев, Елена Григорьева һәм Елизавета Малова иҗатына багышланган кичә узды*

**Фирая МОРАТОВА**

***Дусларга, авылдашларга, туган җиргә дан җырлаган “Изгеләр чишмәсенең суын эчсәм...” дип аталган шигъри-музыкаль кичә зур бәйрәмгә әйләнде. Сагынышкан якташлар очрашты, Владимир авылы шагыйрьләре үз шигырьләрен үзләре сөйләде. Кеше бит шулар белән бәхетле!***

***Кичәнең сценарий авторы һәм алып баручысы – “Туганайлар” газетасының баш редакторы Юлия Губина да бу шагыйрьләр турында “матурлыкны күреп, аңа дан җырлаучылар”, дип әйтте.***



● *Беренче рәттә: Е.Григорьева (сулдан дүртенче), Г.Ибушев, Е.Малова — авылдашлары һәм районташлары белән.*
*А.Кондратьева фотосы.*

**Елизавета Малова**

Иң беренче итеп, тамашачы каршына гомеренең хезмәт еллары Түбән Камадагы “Нефтехим” җәмгыяте белән бәйләнгән Елизавета Малова чыкты. 12 балалы Маловлар гаиләсендәге кызларның иң өлкәне булган Елизавета мәктәптә укыганда ук каләм тибрәтә. Алып баручы Владимирдагы туган йортында яшәүче Елизавета белән таныштырып, “2016 елда аның “Сине уйлап” дигән шигырьләр китабы басыла – кеше язмышлары, үз тормышындагы шатлык-көенечләре дә, дөрес яшимме-юкмы кебек фәлсәфи уйлары да шул китабында урын алган”, дип әйтеп үтте.

– Бик борчылган идем, барыгызның да үзебезнекеләр икәнен белгәч, тынычландым. Кырда, су буенда йөргәндә, чишмәгә төшеп менсәм дә, утка карап утырсам да, күңелдә шигырь туа, – дип, Елизавета үзе иҗат иткән шигырьләрне укыды:

*...Югалтулар күп инде ул,*
*Табасың, югалтасың,*
*Яхшыга юрап һәр таңны,*
*Күңелне юатасың...*

**Елена Григорьева**

Татарстанның атказанган артисты, “Бәрмәнчек” дәүләт фольклор ансамбле оркестры артисты Елена Григорьева үз шигырьләрен 2023 елда гына ВКонтактедагы сәхифәсенә куя башлаган.

– Владимирның Арт урам кызы икәнемне беләсездер, ул урамдагы яшьтәш малайларның атаманы идем, – дип, уены-чыны белән сөйләде Елена. Аның үз укуында яңгыраган фәлсәфи шигырьләре тамашачыны уйландырды, усаллары гаҗәпкә калдырды, шаяннары исә елмайтты:

*...Буралап өйгәнне*
*чыралап ваткан бар, –*
*Бер эзләп тапканны*
*югалтып-тапкан бар...*

Тамашачы арасында Еленаның “Гөргөри кияүләре +” тамашасында Палый карчыкны оста уйнавына игътибар итүчеләр, шул роле турында сораучылар да булды

– Кечкенәдән артист булырга хыялландым. Дәдәй: “Кая инде сиңа артист булу?! Әнә, музыкант бул”, – диде. Берсендә Георгий дәдәй безгә мендe дә, гармунда уйнаганымны күрде, шулай итеп, иҗат язмышым хәл ителде... Палый ролен ярты ел өйрәндем. Аз сүзле бу рольдә Палый образын ачып бирергә кирәк. Ирем Георгий эштән кайтканда, аны Палый рәвешенчә сөйләшеп каршы ала идем. Гастрольләргә барганда, “әнекәем, шушы әбине дә алып йөрисезме?!” дип гаҗәпләнәләр иде, – дип көлдереп тә алды Елена.

**Георгий Ибушев**

– Шагыйрь һәм җырчы карендәшебезнең үз шигырьләре дә җыр кебек агыла. Аның 2007 елда – “Рәхмәт сиңа, җыр”, ә 2019 елда “Балачакны сагынып” дип аталган китаплары дөнья күрде, – дип, алып баручы тамашачы каршына Георгий Ибушевны чакырды.

– “Җырлама, күп җырлыйсың, бәхетеңне җырлап бетерәсең”, дип әйтә иде әни, – дип тәмләп сөйли башлады Георгий Мефодиевич һәм шигырьнең кайчан, нинди шартларда туулы тукталды. – Күңелгә, мәсәлән, “җиргә кемдер” дигән сүз килеп керә дә, шуннан соң шигырь үзеннән-үзе агыла башлый:

*...Мин бу җиргә*
*кемдер салып киткән*
*Җиңел сукмак эзләп килмәдем.*
*Ят сукмакка*
*сыймас иде минем*
*Җыр-моң тулып*
*ташкан хисләрем...*

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев бер кочак шигырьләрен укыды, шигырьләре арасында туган авылы Владимир, анда үткән балачагы, авылдашлары белән бәйле истәлекләрен яңартты.

Бу кичә – Владимирның “Талир тәңкә” ансамбле, укытучылар Елена һәм Николай Бачковларның җырлары, “Бәрмәнчек” дәүләт фольклор ансамбле солистлары Ольга Бачкова, Денис Михайлов, Владимир клубы һәм, шулай ук, “Талир тәңкә” җитәкчесе Галина Михайлованың җырчы шагыйрь Георгий Ибушевның “Микай” поэмасыннан өзекне яттан сөйләве белән үрелеп барды.

**Язучылар союзына юллар ачылсын**

**Людмила БЕЛОУСОВА**, *республика керәшен иҗтимагый оешмасы башкарма комитеты җитәкчесе, Я.Емельянов исемендәге мәдәни үзәк директоры:*



– Мамадыш ягы – искиткеч төбәк. Албайдан биш Герой чыккан, ә Владимир авылыннан – өч шагыйрь. Бу авылдан талантлы яшь җырчылар да чыккан: бүген “Бәрмәнчек” ансамблендә өч солисты эшли. Әле аларның чиркәү төзеп ятканнарын да әйтик, әлегә клублары юк – иске чиркәү бинасында торалар, бу – зур җазык. Яңа клуб кирәк. Владимирда – әнә шундый эшчән, талантлы халык. Язучылар союзыннан кадерле кунагыбыз Рифат Җамал да арабызда. Чыгыш ясаучыларның иҗаты турында ул үзенең җылы сүзләрен җиткерде, аларга зур бәя бирде. Бу талантлы шагыйрьләребезгә дә язучылар союзына юллар ачылсын һәм яңадан-яңа шигырьләре тупланган китаплары басылып торсын иде.

**Степан СПИРИДОНОВ**, *Мамадыш районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы:*



– Георгий дәдәйнең җырларын ишеткәч, аның үзе белән танышкач һәм үзем мәдәният тармагында эшли башлагач, Владимир авылының талантларга бай икәнен күрдем. Владимирда – әйбәт, җор, ачык йөзле, кешелекле һәм җырга оста, чып-чын керәшен мәдәниятен саклап, алга алып баручы халык яши. Җәкәү йортына, өч туганыбызның шигъри концертын карарга, Мамадыш районыннан тулы бер автобус кеше алып килдек. Шундый якташларыбыз булу – зур горурлык.

**Лидия ПАСЫЕВА**, *Мамадыш районының Усали мәктәбе укытучысы:*



– Җырчы Җәкәү йортында мәнә шушындый бер авыл бәйрәме оештырылганы булмагандыр әле. Әти һәм әни Владимирның затлы нәселләр авылы булуын кечкенәдән күңелемә сеңдереп үстерделәр. Алар сөйләве буенча, Владимирда өй борынча гармунчылар икәнен, анда кемнәрнең матур җырлаганын, ат күтәрерлек һәм тешләре белән берәр капчык он күтәрә торган көчле кешеләр булганын беләм. Георгий Ибушев та, Елена Григорьева да минем туганнарым, ә Лиза Малова – икелэтә туганым: әтисе, әбисе яклап та. Затлы нәселле бу туганнарым белән миңа гел дә шулай горурланырга, ә аларга Владимир данын тагын да күтәрергә язсын.

**Николай БАЧКОВ**, *Мамадыш районының Владимир мәктәбе укытучысы:*



– Укытучы шундый халык, ул барысына да җитешергә тиеш: мәктәптә балаларга белем бирергә дә, өйдә эшләргә дә һәм мондый кичәләрдә катнашырга да. Бу кичәгә килә алуыбыз һәм авылыбызның күренекле кешеләре белән бер сәхнәдә чыгыш ясавыбыз белән, без бик бәхетле. Мондый кичәләр авылның рухи байлыгын барлау, шуны киләчәк буынга тапшыру ягыннан да бик кирәк.

**Ольга ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА**, *Казан шәһәре:*



– Минем өчен бу – өч асыл зат кына түгел, ә озын кыш буе күрми торган авылдашларым белән очрашу да. Кичәнең авылыбызның “Талир тәңкә” фольклор ансамбле чыгышы белән башланып китүе дә күңелгә май булып ятты. Лизаның шигырьләрен кич буе тыңларга риза идем, 4 шигырьне генә миңа аз тоелды. Аның “Еллар үткәч...” дигән шигырен кичәдә яттан сөйләдем дә әле. II керәшен марафоны барышында аның 21 шигырен халыкка җиткерү насыйп булды миңа. Лизаның киләчәк юбилей кичәсе, бәлки, Җәкәү йортында үткәрелер әле. “Таш астыннан чыккан” Елена Григорьева-Данилова баш җитмәслек тирән фәлсәфи шигырьләре белән, язгы ташу кебек килеп керде шигърият дөньясына. Георгий Ибушевның җырчы гына түгел, олпат шагыйрь дә икәнен белмәгән кеше юктыр. Георгий кебек, туган авылы табигатенең матурлыгын шигъри юлларга салган, нәни баладай саф, нечкә күңелле бүтән кешене белмим мин.

**Галина МИХАЙЛОВА,** *Мамадыш районының Владимир авылы клубы һәм “Талир тәңкә” ансамбле җитәкчесе:*



– Авылыбызның күренекле, талантлы шәхесләре белән Казанда очрашу күңелләргә илһам өсти. “Талир тәңкә”дән 8 кеше килдек. Без, Георгий дәдәй өйрәткәнчә, акапеллага да җырлыйбыз. Авылыбыз шагыйрьләре белән горурланабыз, шигырьләрен укыйбыз, сәхнәдә сөйлибез. Клубта аларның иҗат кичәләре үтә. Георгий дәдәйнең, Елизаветаның иҗатына багышланган кичәләр оештырылды инде, киләсе 2025 елда Елена Григорьева белән дә уздырачакбыз. Бүген улым, “Бәрмәнчек” ансамбле солисты Денис Валерьевич та бу кичәдә катнашты.

Кичәнең видеоязмасын шушы QR-код аша кереп, карый аласыз.

2024 гаилә елы

# “Кәбен койдыргач, тезләнеп, бер-беребезнең аягын юдык”

Юлия ГУБИНА

*Татьяна Ефремова җыр сәнгатендә үзен керәшен кызы буларак танытып, халкыбызның гасырлардан сакланып килгән үзенчәлекле, матур культурасын дөньяга күрсәтә*

***“Кряшен чибяре” титулы иясе, талантлы карендәшебез, җырчы Татьяна Ефремова сәхнәдә керәшен җырларын башкару белән танылып китеп, халыкара һәм илкүләм конкурсларда күп мәртәбәләр җиңү яулады. Күптән түгел ул Казахстанда оештырылган “Voice of Turan-2023” халыкара вокал конкурсында катнашып һәм, хәтта, казах телендә җыр башкарып, беренче урынга лаек булды.***

### Үзен тиешенчә тота белә

Артистлар арасында, кара пиар белән мавыгып, үзенә аудитория җыючылар әйтеп бетергесез күп. Татьяна андыйлардан түгел. Ул үзенең социаль челтәрен дә тиешенчә алып бара: керәшен культурасы, профессиональ эшчәнлеге, үзенең тормышыннан пиар, гайбәтләр юк анда.

Былтыр Татьяна белән ире кәбен койдыру җәшереге уздырганнар. “Гаилә дигән төшенчәнең кыйммәте бетте. Яшьләр бераз башлырак булсын иде, болай гына бернәрсә дә эшләнми, шуны аңлатасым килде”, – дип әйтте ул үзенең кәбен койдыру турында язуын.

Татьяна Ефремованың кәбен койдыру турында язганнарын газета укучыларыбызга да тәкъдим итәбез. Укыйк, белик, фикер йөртик һәм яхшыдан үрнәк алыйк!

### Уртак теләк белән

*Узган елның февралендә Булачак ирем миңа кияүгә чыгарга тәкъдим ясады. Бу вакыйгага кадәр, иң элек, без бер-беребезнең тормыш кыйммәтләре белән таныштык. Киләчәк турында сүз кузгаткач, бөтен әһәмиятен һәм җаваплылыгын аңлап, икебезнең дә Ходай каршында кәбен койдырырга теләгебез барлыгы ачыкланды.*

*Бу адымга һәркем дә бармый, чөнки кәбен койдыру — кеше гомерендә бер генә тапкыр була торган вакыйга. Без моны яхшылап өйрәнеп һәм аңлап эшләдек. Тәкъдим ясалганнан соң, кәбен койдыру җәшерегенә әзерләнә башладык. Туйны бер-ике айда әзерләсәк, кәбен койдыруга әзерлек исә күпкә озаграк, җаваплырак булды. Безнең өчен ул бик тә дулкынландыргыч, ә кайвакыт авыр да чор булды.*

***Священник белән киңәшләшү.*** *Ул безгә, чиркәү кануны буенча, гаилә һәм кәбен койдыруның асылын аңлатты; егет белән кыз өчен боларның әһәмияте һәм аңа әзерлек турында сөйләде.*

***Кәбен койдыру датасын билгеләү.*** *Бу көнне священник белән билгелиләр, чөнки бар көнне дә кәбен коймыйлар. Кәбен кою җәшереге – вторник, четверг һәм суббота көннәрендә, шулай ук, ураза һәм дини бәйрәм көннәрендә уздырылмый. Кәбен кою бары тик көндез генә башкарыла, хатын-кызларның күрем көннәренә дә туры килмәскә тиеш.*

***Яшьләр икесе дә чумылган һәм муеннарында кач булырга тиеш.*** *Икесенең берсе башка диндә яки атеист булса, бу да кабул ителми.*

***Ата-ананың бәхиллеге булырга тиеш.***

***Балдаклар.*** *Кияү өчен – алтын, бу – кояш һәм башлык символы. Хатын өчен – көмеш, кояш яктысын чагылдырган ай символы буларак.*

***Әгәр ир белән хатынның берсе бернича тапкыр өйләнгән булса да кәбен койдырылмый.***

*Кәбенне бары тик ЗАГСта гаиләне рәсми теркәгән документ булганда гына койдыралар. Ир белән хатынның язылышмыйча торуын чиркәү кабул итми.*

### Күз яшьләре аша

*Шулай итеп, кәбен койдыру көнен билгеләп, рухи яктан аңа әзерләнә башладык. Рухи чистарыну этабын уздык. Туйга кадәр без иртән һәм кичен чиркәүгә киләүгә йөрдек, священник белән бергә гаилә кыйммәтләре, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр, үзара хөрмәт турында сөйләштек.*

*Кәбен коюга 2 атна кала, 3-7 көн дәвамында кырыс ураза тоту тиеш. Ашауны чикләү авыр түгел, ә үзеңдәге көнчел һәм өстенлек итә торган хис-фикерләрне, начар сүзләреңне һәм ярамаган эшләреңне тыеп тору җиңел түгел. Һәрьяклап үзеңне контрольдә тотарга кирәк.*

*Кәбен кою алдыннан барлык языкларыңны танып, алар өчен үкенү мөһим. Минем өчен монысы бигрәк тә авыр булды. Язык әйтү алдыннан, кичләрен икебез дә кануннар һәм иманнар укыдык. Булачак ирем белән бер-беребезгә үзебез белән булган оятлы хәлләрне, языкларыбызны (начар сүзләр, гамәлләр һәм башкалар) сөйләдек.*

*Язык әйтү иртәнге киләүдән соң булды. Священник янына башта – кияү, аннары кәләш бара. Кулыбызны Библиягә куеп, язык әйттек. Шул мизгелдә кайчандыр әйтелгән сүзләр, башкарылган гамәлләр, языклар һәм уйларыбыз өчен шулкадәр оят булды. Күз яшьләре туктамый акты. Бу хакта чиркәү гөмбәзе астында кычкырып сөйләү бик авыр иде. Ләкин язык әйтеп, өлеш алганнан соң, күңелгә җиңеллек килде.*

*Кич белән, икебез өчен генә, бер-беребезнең аякларын юу йоласы узды. Бер-беребез алдында тезләнеп (бу – арада горурлык булмаска тиешлеген аңлата) аякларыбызны юдык. Бу – бер-береңә хөрмәт күрсәтү символы, шулай ук, яңа тормыш башлар алдыннан языкларны юып төшерү.*



● Татьяна һәм Владислав — кәбен койдыру җәшерегендә. Фото — шәхси архивтан.

Җолаларыбыз

# Олы көн кайда, ничек үткән?

***Республикабызның карендәшләр күпләп яши торган авылларында һәм, шулай ук, шәһәрләрдә Олы көнне зурлап бәйрәм иттеләр: һәр йортта кулич пеште, күкәй манылды; чиркәүгә киләүгә бардылар.***

### Шәһәр һәм районнарда

**Дорга**да (Балтач районы), Борис Андреев хәбәр иткәнчә, иртәнге дүртләрдә үк капкалар ачып куелып, балалар йорттан-йортка йөргән. Настоятель Сергей килеп, чиркәү урынында киләү үткәрелгән.

**Казан**дагы Тихвин чиркәвендә дә бәйрәм киләве югары дәрәҗәдә узган. Киләүгә карендәшләр Казанның барлык почмакларыннан җыелганнар.

**Колбагыш**ка (Теләче районы), Олы көн бәйрәменә, читтән бик күп кайтканнар. Мария Степанова әйтүенчә, иртәдән үк балалар, урам тутырып, күңелле итеп, манылган күкәй җыйганнар.

**Мәләкәс**тән (Тукай районы) Роза Семенова Олы көнгә 160 күкәй манган, чөнки балалар күпләп йөри, хәтта яңа туган сабыйларны да әниләре бала арбасында йөртә. Төнге уникенче яртыда чиркәүгә киләүгә дә барган халык.

**Село-Чура**да (Кукмара районы) Олы көн киләвенә, башка беркайда булмаганча, халык күп җыелган. Алар, барысы бергә, урам тутырып, Тәре йөрешенә чыкканнар.

**Түбән Кама**да районкүләм Олы көн, беренче мәртәбә, Балчыклы авылында уздырылган. Анда “Сүрәкә” һәм башка фольклор ансамбльләре катнашкан. Олылар да таганда атынган, күкәй тәгәрәтеп уйнаганнар.

**Түбән Юшады**да (Минзәлә районы) иртә таңнан балалар өйләргә кереп, “Христос терелеп торган”, дип йөргәннәр. Яхшы хәбәр өчен хуҗалар аларга Олы көн күкәе биргәннәр. Соңыннан Арзамасовлар йорты янында җыелып, Пасха уеннары уздырылган.

**Югары Бгражда** (Зәй районы) халыкны Пасха күкәе тәгәрәтү уены үзенә җыйган. **Кабан Бастырык**та Клавдия Максимова, күкәй әләшүне, өйгә беренче кергән баланы “черләтү”дән башлаган. Төштән соң, аларны күкәй отышлы уенына чакырган.

**Яңа Балыклы** (Башкортстан, Бакалы районы) мәдәният йорты мәйданында “Пасха шатлыгы балкышы” дигән фольклор сәгать булган. Балалар Христосның яңадан терелүе белән бәйле традицияләр турында ишеткәннәр. Пасха күкәен бизәү ысуллары белән танышканнар. Күкәй тәгәрәтү, “долбянка” уеннары да уйналган.

**Үрәсбаш**тан (Кукмара районы) – Любовь Павлова, **Кырбаш**тан (Саба районы) Елена Филиппова да Олы көн иртәсендә балалар килүгә, бик күп күкәй манып, тәм-том әзерләп куйганнар.

### Балалар бакчасында

Түбән Кама шәһәренең 47нче бакчасындагы “Олы көн” бәйрәмендә балалар Валерия Михайлова, Галина Самойлова җырларын, “Нәни чебиләр” биюен ошатканнар (биючеләр аларга бер кәрҗин Олы көн күкәе бүләк иткән). Апуш китапханәсеннән Ирина Дмитриевна – күкәй бизәү, ә лаеклы ялдагы тәрбияче Гөлнур Харисовна мунчаладан курчак ясау буенча мастер-класс оештырганнар. “Олы көн” иртәсе “Күкәй тәгәрәтү”, “Төсле тасмалар”, “Иптәшеңә күкәй бир”, “Төсле кулчатыр” түгәрәк уеннары белән үрелеп барган.



● Село-Чура мәктәбендәге бәйрәмдә. А.Кондратьева фотосы.

### Село-Чура мәктәбендә

Я.Емельянов исемендәге мәдәни үзәк хезмәткәрләре Село-Чура мәктәбендә (Кукмара районы) Олы көнгә багышланган интеллектуаль уен оештырды. “Кто хочет стать миллионером” форматындагы театральләштерелгән тамашада 40тан артык укучы катнашты.

***Җырчы Вадим Захаров социаль челтәрдәге котлавында “Олы көн күкәй бәйрәме түгел, ул – Христосның терелеп торган көне. “Христос терелеп торган, чынлап терелеп торган!” дип котлашыйк”,— дигән.***

**Артист**

# Регина Павлова: “Ым кагучылар бар, йөрәгемне яулаучы юк”

**Алина КОНДРАТЬЕВА**

*Мамадыш районының Юкәче авылы кызы Регина ПАВЛОВА — “Бәрмәнчек” дәүләт фольклор ансамбле солисткасы. Нечкә күңелле, хыялый дип әйтә ул үзе турында. Елмаюы белән үзенә карытып торган карендәшебез белән иҗаты, шәхси тормышы турында сөйләштек. Күңелендә йөрткән зур хыялы белән дә уртаклашты.*



Регина Павлова.

**– Регина, җырлау сәләте сиңа бәләкәйдән бирелгәнме?**

– Әби-бабайлар җыруга оста булган, бәйрәмнәрдә дә башлап җырлаганнар. Ә гаиләдә иҗат юлын сайлаучы – бер мин. Балалар бакчасына йөргәндә әни беренче тапкыр сәхнәгә чыгарды. Шуннан конкурсларда, концертларда катнаша башладым. Шулай да, 11 класс бетергәч, җырны сайламадым, Казан дәүләт университетының экология факультетына кердем. Ә ярты елдан соң “Бәрмәнчек”кә киттем. Яңа уку елында Казан дәүләт сәнгать институтына, Винера Ганиеваның “Сольное народное пение” кафедрасына укырга кердем. Студент еллары эш белән уку йорты арасында узды.

**– Ялгызың җырларга теләмәдеңме?**

– Ялгыз җырлау турында уйласам да, андый теләгем тиз сүрелде. Үземне ансамбльгә багышладым, инде 11 ел эшлим. Тормышымны фольклордан, халык җырларыннан башка күз алдына китермим. Ходай кушмаган эш юк диләр, шулай тиеш булган, димәк.

**– Ансамбльдә эшләү җиңел түгелдер.**

– Эшкә урнашкач, ярты ел чамасы авыррак булды. Хәзер инде сәхнә – минем өчен эш урыны. Еллар узу белән дулкынлану хисе дә бетте. “Бәрмәнчек”тә бер гаилә кебек без, керәшен фольклоры җанатарлары эшли. Иҗат дөньясында бу ансамбльдә үз урынымны таптым.

**– Башка җирдә эшләп карау теләгең булмадымы?**

– 22-23 яшьтә беренче тапкыр самолетка утырдым. “Бәрмәнчек” белән Болгариягә очтык. Бортпроводницаларны күрдем һәм бу профессиягә гашыйк булдым. Кайткач, “Кайда укыталар?”, “Күпме укырга?” дип, эзләнә башладым. Яшермим, 3 тапкыр Мәскәүдә махсус әңгәмәдә булдым. 2019 елда беренче тапкыр барып, күреп кайттым. Анда инглиз теле бераз “подвел”. Ә аны яхшы белү – төп критерий. 2020 ел башында бер авиокомпаниягә үттем, укырга барырга тиеш идем, ләкин ковид аяк чалды. Күңелдә һаман бортпроводница булу, гражданская авиациядә эшләү хыялы яши.

**– “Бәрмәнчек” ансамбленең “Гөргөри кияүләре” тамашасында үзеңне актриса буларак сынап карадың...**

– Андагы Үринә роле, актриса буларак, беренче тәҗрибәм. Балачак хыялым чынга ашты. Ул вакытта Гөргөри ролендәге артист Николай Дунаевның киңәшләре бик ярдәм итте. Кызганыч, аның белән озак эшли алмадык. Анда алган тәҗрибә әле хәзер театральләштерелгән тамашаларда да ярдәм итә. Аннан соң Гөргөри ролендә Олег Фазылҗанов булды. Аның белән спектакльгә яңа сулыш кереп киткәндәй булды.

**– Шундый керәшен туе ясар идеңме?**

– Әгәр ясасаң, аны җиренә җиткерергә кирәк – спектакльдәге кебек, элгәречә, йоласына туры китереп. Минем өчен туй – ике кешенең бәйрәме, әти-әниләрне таныштыру да. Яшь барган саен фикер үзгәрә. Хәзер инде мин, гомумән, зур туй ясарга теләмим.

**– Йөргән егетең бармы?**

– Ым кагучылар бар, ләкин йөрәгемне яулап алучы юк. “Смс”лар гына язып ятучыларны яратмыйм, бала-чагалык. Егет кешенең җитдилеге эшендә күренә. Беренче адым ясап, күрешергә чакырсалар, башка эш. Ләкин хәзерге егетләр ялкаурак. Ир-ат күп сөйләшмәскә, тормышка үз планнары булырга, гаилә алып барырга тиеш. Тагын бер мөһим момент: бер-береңне тулыландырып тору.

**– “Кряшен чибәре-2008” титулы иясе дә бит әле син.**

– Анда катнашканда 15 яшьтә идем. Шул елны 1нче урынга 50 мең сум акчалата бүләк бирделәр. Хәзер конкурста катнашучы кызларга ак көнләшү белән карыйм. Сәхнәгә яхшы әзерлек этаплары узып чыгалар, матур кием, барысын да осталар бизәндерә... 2019 елда, Питрауның 20 еллыгы уңаеннан, 1нче урынны алган кызларны җыйдылар. Үзебезне тагын бер кат “Кряшен чибәре” итеп хис иттек, шул вакытка кайткандай булдык. Без “Бәрмәнчек” белән “Кряшен чибәре” сәхнәсендә ел да чыгыш ясыйбыз, шунда читтән күзәтәм кызларны. Чыгыш ясыйсыбыз булмаса, рәхәтләнеп карар идем.

**– Буш вакытың ничек уза?**

– Хоббилар күп. Сәяхәт итәргә яратам. Кем белән барыйм икән дип, көтеп утырмыйм, үзем генә билет алып, рәхәтләнеп чыгып китәм. Аеруча Кавказны яратам. Кая гына барсам да керәшен кызы дип, керәшеннәрнең кем икәнен сөйләп, таныштырып йөрим (көлә). Сәяхәт, таулар, табигать мине тынычландыра, илһамландыра, мин шулай көч җыям. Телләр өйрәнәм: инглиз, төрек... Хыялымда – кытай телен өйрәнү. Буш вакыт булдымы, китаплар укыйм, Казан урамнары буйлап йөрим, ял итәм. Авылны да онытмыйм.

**– Киләчәккә син ниндирәк планнар корасың?**

– Кызганыч, әлегә үзем генә җырлар яздырырга вакыт җитеп бетми, ә шулай да уйлар бар. Ул этнофолк стилендә булачак. Күбрәк, халык җырларына, керәшен җыруларына бераз заманча сулыш кертеп, яшьләр дә тыңларлык итеп яздырыр идем. Иҗат кешесе җырдан башка тора алмый. Башка эшкә китсәм дә, иҗатта булачакмын.

**– Хәзерге эстрада, җырчылар турында ни уйлыйсың?**

– Мин эстрада җырчысы түгел. Хәзер үзен артист дип уйлаган һәр кеше җыр яздыра да, клип төшерә дә сәхнәгә чыга. Хәзер бездә цензура да юк. Күпләр җырның сүзләренә дә артык игътибар бирмиләр. Сикереп биеп булса, ул инде “хит”. Кызганыч, халыкка да шул ошый.

**– Әңгәмә өчен рәхмәт, Регина!**

2024 гаилә елы

# “Мин – ирдән, балаларыбыз әтидән уңдык”

**Алинә ГАЛИМҖАНОВА**

***Гаилә – тормышның нигезе. Ата-ана аның тоткасы булса, балалар – гаиләнең көзгесе, диләр. Кайбыч районының Олы Тәрбит авылында яшәүче Надежда һәм Сергей ГАЛКИННАР шушы әйтемгә туры килерлек үрнәк гаилә кора алганнар.***

### Мәктәп елларыннан ук

Сергей һәм Надежда икесе дә Тәрбит авылыннан булганга, мәктәптә дә 11нче класска кадәр бергә укыганнар. Икесе дә – ишле гаиләдән, Сергей – 8 баланың, ә Надежда 7 баланың төпчеге. Ике гаиләдә дә балаларны әниләре үзләре генә тәрбияләгән. Надежда белән Сергейга, әтисез калганда, 6 яшь булган... Күп балалы гаиләдә үскәнлектән, йортларында бала тавышы яңгырап торганын ярата алар.

– Мине яратып йөргәнен әллә кайчан белә идем инде. Һәрвакыт “миңа синнән башка беркем дә кирәкми”, дип әйтә иде. Кияүгә чыкканда 18-20 яшьтә түгел идем, олы кеше акылы белән уйладым. Мәктәп елларыннан ук Сережаның тыйнак, акыллы икәнен белдем. Яшь вакытта дуслары клубка чыкканда да Сережа өйдә, үзе теләп, әне-сеңелләрен карап утыра иде. Миңа киләчәктә ныклы терәк булырлык, балаларыбызны тигезлектә үстерә алырлык ир кирәк иде, – дип, бәхетле гаилә тормышына китергән елларны искә төшерде Надежда.



Галкиннар — әниләре Валентина, тәрбияче Гөлназ белән. Фото — шәхси архивтан.

### Өч бала үстерәләр

Надежда хыялланганча, Сергей бик әйбәт ир һәм әти була. Аларның икесенә дә – 35әр яшь, инде 7 ел ныклы һәм тату гаилә булып, 3 бала үстерәләр. Олы уллары Раянга – 6 яшь, уртанчы уллары Макарга – 4 яшь, төпчекләре – кыз, анысы – 2 яшьлек Ралина. Әле кечкенә булсалар да, ярышларда, әдәби конкурсларда гаиләләре белән катнашып, призлы урыннар яулыйлар. Сергей юл төзелеше компаниясендә эшли, Надежда – декрет ялында.

– Сережа 15 көн эшли, 15 көн ял итә. Ял вакытында ул һәрвакыт балалар белән, аларны миннән дә әйбәтрәк карый. Туачак сабыйларыма бала җанлы әти теләгән идем, нәкъ шулай булып чыкты. Мин – ирдән, балаларыбыз әтидән уңдык, – дип сөйли күп балалы әни.

Яшь гаилә төп йортта яши. Надежда әйтүенчә, ике якның да әниләре балаларны карарга булыша.

### Керәшен җанлы гаилә

– Өч бала үстерү җиңелме-кыенмы – белмим, төрлесе була. Иң мөһиме – исән-сау булсыннар. Аларга дөрес тәрбия бирү өчен, бар тырышлыгыбызны куябыз. Без – керәшеннәр, дип, йола-гадәтләр белән таныштырып торабыз. Шуңа да Пасха бәйрәмен ел да көтеп алалар, урам буйлап, күкәй җыеп йөрү ошый аларга. Троица бәйрәмнәрендә дә гаиләбез белән җыелабыз, туганнар да кайта, – дип горурланып сөйли Надежда.

Ул үз туйларының чын керәшенчә, йола-гадәтләргә туры китереп узганын да искә төшерде. Надежданы, элеккедән килгән гадәт буенча, башта сорап киткәннәр, туйларында да керәшен йолалары үтәлгән. Кыз ягыннан әнисе бирнә алып килгән: чиккән мендәр тышлары, чиккән тәре алды сөлгеләре... Беренче көнне бәйрәм кафеда булса, икенче көнне – кияү, ә өченче көнне – кыз ягында.

– Тиздән – бакыр туебыз. Шул уңайдан, кәбен койдырырга уйлыйбыз, – диде Надежда.

### Һәрбер кешенең үз пары булсын

Югарыда телгә алынганча, Сергей белән Надежда бер-берсен мәктәптә укыган чактан ук беләләр һәм бер-берсен яратуларын аңлап алуга ук, уртак гаилә сукмагыннан атларга булганнар. Хәзерге яшьләр кебек озак еллар очрашып йөрмәгәннәр.

– Бүгенге көндә яшьләр гаилә коруга җиңелрәк карый кебек. Хәзер бит бишәр ел очрашып йөриләр, бергә торалар, аннан соң бер-берләреннән туеп, аерылышалар. Ир белән хатын булганда башка төрле бит ул. Озаклап очрашып йөрүләрне аңламыйм, үзебезнең алай булмагангадыр инде. Һәрбер кеше үз ярын табып, матур гаилә корсын һәм сау-сәламәт балалар үстерсен иде, шуннан да зуррак бәхет юк бит ул. Яратасыз, хөрмәт итәсез икән, өйләнешегез, – дип, замана яшьләренә әйтәсе киңәшен дә безнең “Туганайлар” аша җиткерде Надежда.

podpiska.pochta.ru